СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» 12. 2025 ел Алабуга шәһәре № 25

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 26 февралендәге 157 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2008 елның 26 февралендәге 157 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәт вазифаларын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белемгә ия булу - вазифаларның иң югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазифалардан тыш; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазифаларның иң югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазифаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белемгә ия булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең иң югары вазифалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.

Вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап аның вазифаи инструкциясенә бәйле рәвештә билгеләнә.

Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.».

2. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов